КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 октябрь г.Казань № 829

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 5 июль, 638 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 5 июль, 638 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 октябрь, 1288 нче; 2024 ел, 16 июль, 571 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исеменә татар текстында «исәптән чыгару турында» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны туктату турында» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «исәптән чыгару турында» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны туктату турында» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин ителгән, төгәлләнмәгән төзелеш объектларын яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларының төгәлләнмәгән төзелешенә сарыф ителгән чыгымнарны исәптән чыгару турында карарлар кабул итү кагыйдәләрендә:

карарның исеменә татар текстында «исәптән чыгару турында» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны туктату турында» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта татар текстында «исәптән чыгару турында» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны туктату турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле пунктлар өстәргә:

«19. Туктату турында карар проект һәм (яки) эзләнү эшләренә карата кабул ителә.

20. Туктату турында карар түбәндәге нигезләрнең берсе булганда кабул ителә:

а) капитал салулар өч ел элек проект документациясе расланган проект һәм (яки) эзләнү эшләренә кертелә;

б) проект һәм (яки) эзләнү эшләре федераль башкарма хакимият органнарына һәм җирле үзидарә органнарына тапшырыла.

21. Туктату турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый акты рәвешендә кабул ителә.

22. Туктату турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) төзү максатларында проект һәм (яки) эзләнү эшләре башкарылган капиталь төзелеш объекты төзелешен гамәлгә ашыруга каралган бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы (алга таба – бюджет акчасы белән баш эш итүче) исеме;

б) төзү максаты белән проект һәм эзләнү эшләре башкарылган капиталь төзелеш объекты исеме;

в) башкарылган чыгымнарның гомуми күләме;

г) алга таба капитал салуларны гамәлгә ашыруның мөмкин булмавына һәм (яки) максатка ярашлы булмавына нигезләү.

23. Туктау турында карар проекты бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан әзерләнә һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (транспорт инфраструктурасы өлкәсендә проект һәм (яки) эзләнү эшләренә башкарылган чыгымнар буенча), Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, төзү максаты белән проект һәм эзләнү эшләре башкарылган, территориясендә капиталь төзелеш объекты урнаштыру планлаштырылган җирле

үзидарә органына (алга таба – җирле үзидарә органы), мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан проект һәм (яки) эзләнү эшләрен башкару һәм финанслау турында карар кабул ителгән республика башкарма хакимият органына җибәрелә.

24. Әлеге Кагыйдәләрнең 23 пунктында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органы тарафыннан туктату турында карар проектын килештерү срогы ул кергән көннән алып 14 календарь көннән артмаска тиеш. Әлеге срок эчендә җавап булмаса, туктату турында карар проекты килештерелгән дип санала.

25. Кисәтүләр яки килештерүдән баш тартулар булганда, туктату турында карар проекты бюджет акчасы белән баш эш итүчегә дәлилләнгән нигез белән кире кайтарыла. Җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, туктату турында карар проекты әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә кабат килештерүгә җибәрелә.

26. Әлеге Кагыйдәләрнең 23 пунктында күрсәтелгән республика башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органы тарафыннан килештерелгәннән соң, туктату турында карар проекты әлеге Кагыйдәләрнең 22 пунктында каралган документлар һәм белешмәләр белән бергә бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин